КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 июль г.Казань № 894

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссиясе турында» 2004 ел, 22 декабрь, 551 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссиясе турында» 2004 ел, 22 декабрь, 551 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 30 март, 135 нче; 2007 ел, 12 октябрь, 553 нче; 2008 ел, 4 февраль, 62 нче; 2010 ел, 23 сентябрь, 758 нче; 2010 ел, 25 ноябрь, 933 нче; 2011 ел, 13 май, 390 нчы; 2011 ел, 26 декабрь, 1071 нче; 2014 ел, 29 гыйнвар, 48 нче; 2014 ел, 10 июнь, 392 нче; 2014 ел, 25 сентябрь, 677 нче; 2014 ел, 17 ноябрь, 885 нче; 2015 ел, 3 июнь, 403 нче; 2016 ел, 21 ноябрь, 864 нче; 2017 ел, 28 октябрь, 814 нче; 2018 ел, 14 апрель, 249 нчы; 2020 ел, 1 декабрь, 1085 нче; 2022 ел, 8 апрель, 337 нче, 2023 ел, 4 апрель, 403 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссия эшчәнлеген тәэмин итү тәртибендә:

4 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

унбишенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссиядә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкилләрен алмаштыру тәртибенең 2 пунктының дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин